# ГАБДУЛЛА

Габдулла әфәнде уянып китте. Язгы кояшның нуры да түбәнге кат өйгә аз гына кергән иде. Таш өйнең юеш исе борынга кереп әллә нинди кәефне җибәреп тора иде. Күрше бүлмәдәге челтер-челтер чынаяк тавышлары ишетелә иде. Чыгыр-чагыр иткән ишек тавышы да өйдәшләренең торуларын белдерә иде.

Йоклар-йокламас торган Габдулла әфәндене бу тавышлар бөтенләй уятып җибәрде. Ул юрган астында сузылып кына киерелеп куйды. Бармак очларыннан башлап түбәсенә кадәр әллә нинди бер авыру хис кылды. Аякларының балтырлары зур гер таккан кебек булып тора иде. Аяк бармаклары эскәнҗә берлән кыскан кебек булып эченнән генә сызып сызлый иде.

Одеялы начаррак булганга аркасы өши иде. Аркаларын елытыр өчен тагы бераз чалкан ятмакчы булып, Габдулла әфәнде әйләнеп ятты. Тагы авырта торган төшкә икмәк катысы тигән кебек бөтен тәне сызлап китте.

Габдулла әфәнденең күзе идәнгә төште. Идәндә кичә кич берлән укып яткан китабы ачык көенчә ята иде. Аның янында бик чыланып беткән балтыр чүпрәге, аның берлән беррәттән төбе тишек бер итеге. Ерак түгел генә өстәл өстендә бик күп чуалган кәгазьләре, әллә ничә ачып куйган китаплары сәленеп-сәленеп төшкән гәзитәләре күренә иде.

Стенадагы китаплар куяр өчен ясалган шүрлекнең өстендә бер фурашкы, бер татар бүреге, бер нимес фурашкысы, бер салам эшләпәсе ята иде. Караватта кара керләр янында иске генә кәләпүш тә ауналып тора иде. Караваттан ерак түгел генә урындык өстендә кара күлмәк һәм билгә бәйләр өчен каеш сузылып ята иде. Стенадагы чөйдә бер пальтә, бер татар казакие, бер тужурка эленеп торалар иде. Боларның барысын да кибеттән чыкканнарына шактый еллар үткәнгә изелеп бетеп, киемлек калыбын аз гына югалтмаганнар иде.

Габдулла әфәнде боларны күздән кичергәч, баш астындагы мендәр астына кулын җибәрде. Кулы кичә баш астына куеп яткан прокламацияләренә барып тиде. Ул үзенең кичәге эшләрен уйлый башлады. Иртә берлән Уралның аргы янына чыгып приказчиклар берлә аларга социализм фикерен аңлатыр өчен сөйләүләре хәтеренә төште.

Аның артыннан ук татар «Марсельезасын» ерлап Урал буйлата кайтулары исенә төште. Аның соңында шәһәрнең икенче кырыенда тегермән эшчеләре янына барып, алар берлән әллә нинди бүрәнәләр өстендә эшчеләр союзының идеясен аңлатуы күз алдына килде. Аннан соң шәкертләр түгәрәгенә барып, аларга социал-демократлар берлән социалист революционерлар арасындагы аерманы сөйләде. [.....] хәтеренә килде.* Аның соңында [...] авылга китә торган кешеләргә прокламация бирүләре, аннан соң башка иптәшләре берлән күрешеп иртәгеге көнне нишләргәлеген сөйләшеп куюлары хәтеренә килде.

Бүген тагы тегермәнгә барырга тиешлеге, бу көн тагы тимер күпер артына барып тимер юл эшчеләре берлән түгәрәк ясарга тиешле хәтеренә төште.

Иртәгеге көннең дә шулай үтүе, аның соңгы көннәренең дә шулай үтәчәге күңеленә төште.

Үзенең дүрт-биш айдан бирле шулай итеп әле бер шәһәрдә, әле бер шәһәрдә идән асты эшләрен эшләп йөрүе, шәһәр саен үзенә бер кеше булып күренеп, әллә нинди ялган паспортлар берлән йөрүе хәтеренә килде. Шул эш өчен үзенең ата-анасыннан, йорт-йереннән аерылып, бөтен гомерен, бөтен рәхәтен шуңарга корбан кылуы, шуңардан башкадан ләззәт алмавы күңеленә төште, күз алдына үзенең Уфада кылган эшләре күренә башлады.

Авыл халкының моның прокламацияләрен укып аңлаулары, эшчеләрнең шуларны аңлап, [.....] хәлләрен яктыртулары, шәкертләрнең шул мәсьәләләрне аңлап җитәр өчен укырга тотынулары күңеленә килде. Әллә кайдан ерактан гына татар «Марсельеза»сы ишетелгән кебек булды. Үзенең кылган хезмәтләренең файдасы, чиккән мәшәккатьләренең йемеше бик зур

булачагына күңел ышанып шатлана башлады. Шул арада моның бу шәһәрдәге исеме берлән хозяйкасы: «Чәй өлгерде!» — дип ишек какты.

Габдулла әфәнде, чәй эчеп, тагы шул эшләргә чыгып китте. Тагы прокламацияләр таратты, тагы түгәрәккә барды. Тагы үзенең сасыган бүлмәсенә кайтып, иске одеялны ябынып ятты. Тагы шул ук китапны укырга тотынды. Иске тормышларны ташлап, иске йомшак урыннар, елы юрганнарда ятуыннан бөтенләй бизеп, татлы ашауларын, тыныч торуларын күңеленнән чыгарып, ачлы-туклы торып, һәр минутта җаныннан аерылу ихтималы булган революция юлына керде, революция генә халыкны рәхәткә ирештерә дип ышанганга, үзен-үзе революциягә корбан кылды.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

* Җөмлә өзелгән. Күптокталар текстның типографиядә басканда кыскартылуын аңлата.

**Габдулла.**—«Таң йолдызы» гәзитәсенең 1906, 24 окт. (57 нче) санында «Фельетон» исеме белән басылган. Имза: Чыңгыз. Исхакыйлар заманында әдәби жанр атамалары бик үк төгәл кулланылмаган. Хикәя, повесть рәвешендәге әсәрләрне «роман» дип атаганнар. Шулай ук теләсә нинди эчтәлектәге һөм зурлыктагы проза әсәрләрен «фельетон» дип атау да еш очрый. Шулай да бу жөһөттөн Г. Исхакыйның чит илдә язылган бер истәлегендә: «Язылган мәкаләләрнең басылуы авырая. Күбесенең яртысы гына басылырлык табыла... Бу бигрәк тә минем өчен авыр тоела. Мин кечкенә фельетоннар төсендә сәяси тәнкыйть язарга керештем», дигән сүзләренә дә игътибар итәргә туры килә *(Гәзцтәчелек эшендә егерме биш ел.— «Яңа милли юл», 1931 ел,* 5 *сан).*

Хикәядәге вакыйгалар Г. Исхакыйның үз тормышыннан алынган. Хикәя герое Габдулла кебек үк ул да авылларда, шәһәрләрдә митинглар үткәреп, «социализм фикерен аңлатып», прокламацияләр таратып йөри, «шәкертләр

түгәрәгенә барып, аларга социал-демократлар берлән социалист революционерлар арасындагы аерманы» сөйли, һәм Габдулла кебек үк «чиккән мәшәкатьләренең йемеше бик зур булачагына күңеле ышана». Тексттан күренгәнчә, хикәя цензура тарафыннан берничә урында кыскартылган.

Хикәянең исеме шартлы рәвештә куела.

*Татар «Марсельеза»сы*—«Марсельеза»—француз революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. Сүзләре һәм музыкасы 1792 елда Страсбургта К. Ж. Руже де Лиль тарафыннан язылган. Россиядә 19 гасырның 80—90 нчы елларында эшчеләр һәм интеллигенция арасында «Марсельеза» көенә җырлана торган революцион җыр таралган булган. Аны «Эшчеләр Марсельезасы» дип атаганнар. Текстын П. Л. Лавров язгаң. «Марсельеза»ны татарчага С. Рәмиев тәрҗемә итә. Җырның беренче куплеты:

Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Ул тормыштан илгә файда юк.
Булса, байлар илә тик түрәләр
Аркабызда рәхәт күрәләр.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 271-272.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова